**Муниципаль этап**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре жаваплары**

**2022-2023 нче уку елы**

**7 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 150 минут**

**Гомуми балл – 70**

| | Максималь балл | Җавап ларга куелган балл |
|---|---|---|
| **1. а) Әлеге билгеләмәгә туры килгән төшенчәне язып куегыз.**<br>Нигезендә фантастик образ яки күзаллау яткан халык хикәясе ..... дип атала.<br>Җавап: Легенда | **2** | |
| **ә) Бу жанрга караган үзегез белгән әсәрләрнең исемнәрен языгыз.**<br>Җавап: «Ярканат ничек итеп дөньяны саклап калган?», «Зөһрә йолдыз» һ.б. | **4** | |
| **б) Шул әсәрләрнең берсенең эчтәлеген языгыз.**<br>Җавап: «Зөһрә йолдыз» легендасы.<br>Заманында Зөһрә исемле бик матур, бик акыллы, бик эшчән кыз булган. Аның булдыклылыгына, уңганлыгына, һәр эшне белүенә, кешеләргә карата игелекле булуына бөтен тирә-як исләре китеп сөйли икән. Аның бик усал үги анасы булган, ул Зөһрәдән бик көнләшеп, һәрвакыт юк сәбәпләр белән аны тирги, ачулана, кыен эшләр куша икән.<br>Шулай беркөнне, иртәдән кичкә кадәр эшләп бик арып кайткач, Зөһрәгә үги анасы төпсез савытка су ташырга кушкан, үзе бик ачуланып:<br>— Әгәр дә таң atканчы тутырмасаң, йортыма аяк басасы булма, кыйнап үтерермен, — дигән.<br>Зөһрә, бер сүз дә әйтмичә, көянтәсе белән чиләкләрен күтәреп суга киткән. Көн буе эшләүдән куллары талган, аяклары йөрүдән көчкә-көчкә генә атлыйлар, җилкәләре буш чиләкләр күтәргәнгә дә сызлана икән. Бик матур айлы кич булган.<br>Күңеле һәрвакыт яхшылыкта булганга, Зөһрәне бер якты йолдыз һәрвакыт күзәтеп торган икән, менә шул, җиргә атылып, аны нурларына чолгап күтәрә башлаган. Зөһрә үзе дә каядыр күтәрелгәнен сизгән, чиләкләре җиңеләйгәндәй булган, күңеленә бик йомшак, бик рәхәт булып киткән. Шунда озын керфекле күзләрен ачып җибәрсә, үзен ай уртасында күргән. Шулай итеп, ул айда калган. | **6** | |
| 2. а) **Кайсы язучы турында сүз баруын билгеләгез.**<br>Бу язучының үсмер чагы сугыш елларына туры килә. Сугыш беткәч, ул Казанга килә, кичке урта мәктәпне тәмамлый. Белемен тирәнәйтү максаты белән, Мәскәүдә Язучылар берлегенең югары әдәби курсларында укый. Әдәби эшчәнлеген ул өлкәннәр язучысы буларак башлап җибәрә. Балалар әдәбиятына бераз соңрак килә. Балалар өчен ул күбрәк кызыклы юмористик шигырьләр язган. Аның әдәби герое — шаян, шук, тапкыр һәм акыллы Шәвәли исемле малай.<br>Җавап: Шәүкәт Галиев | **4** | |
| **б) Бу язучының кайсы әсәрләрен беләсез? Шуларны языгыз.**<br>Җавап: «Шәвәли маҗаралары», «Атлап чыктым Иделне», «Светофорның өч күзе», «Туган телем», «Аталы-уллы солдатлар» һ.б. | **5** | |

| | | |
|---|---|---|
| **3. Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз, сорауларга җаваплар языгыз.** | | |
| «Мәдрәсә янындагы рус классы» дип атала иде бу школа. Алты ел инде ул, үз йорты булмаганга, бер җирдән икенче җиргә, әле – мәдрәсәгә, әле рус мәктәпләренең буш бүлмәләренә күчеп йөрде. Быел гына аңа Госмановлар йортыннан ярты квартал җирдә Петропавловский урамыннан ике катлы таш йорт бирделәр. Кырыкка якын укучысы бар иде бу классның, һәм алар, белемнәренә карап, өч бүлеккә бүленгәннәр иде.<br>Габдулла, Галекәй белән, школаның класс урнашкан өске катына менеп китте. Алар кергәндә, өске катның биек түшәмле зур һәм якты бүлмәсе озын парталарга утырышкан балалар тавышы белән гөж килеп тора иде. Габдулланың яңа эшләнгән мондый озын һәм биек парталарны үз мәдрәсәләре белән янәшә Нури хәлфә мәктәбендә күргәне бар иде инде. Шуңа күрә алар аны артык гаҗәпләндермәде. Ул, Галекәй белән, иң арткы парталарның берсенә барып утырды. | | |
| **3.1. Әсәрнең авторы** Әхмәт Фәйзи | **2** | |
| **3.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Тукай» романы | **2** | |
| **3.3. Рус мәктәбендә уку әсәрнең төп героена нинди мөмкинлекләр биргән? Әсәр эчтәлегенә нигезләнеп фикерегезне дәлилләп языгыз.** | **6** | |
| Җавап: Габдулла Тукай белемне туган телендә яки гарәп, фарсы телләрендә генә түгел, рус телендә дә алырга омтылган. Бу максат белән ул ул рус классына йөри башлый. Рус телен өйрәнү аңа рус әдәбияты белән танышу, рус язучылары, җәмәгать эшлекләре белән аралашу мөмкинлеген бирә. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **4. Шигъри юлларыннан өзекне укыгыз. Биремнәрне үтәгез.** | | |
| ...Ак чәчәкләр ява.<br>Дөнья матур,<br>Шундый матур булып тоела;<br>Күге зәңгәр, гүя йолдызлары,<br>Ак кар булып җиргә коела.<br><br>Туңган тәрәзәне эретеп, мин<br>Мыштым гына карыйм урамга,<br>Ак чәчәкләр ява урамда.<br>Инде хәзер безгә бакчаларда<br>Бастырып булмас тиле йөрәкне<br>(Җил борынга бирер кирәкне).<br><br>Берәү, борын очын кулына тотып,<br>Сүгенә-сүгенә кайта салкыннан,<br>Җил ияреп килә артыннан...<br><br>Тунган тәрәзәне эретеп, ул<br>Мыштым гына карый урамга,<br>Ак чәчәкләр ява урамда... | | |
| **4.1. Әсәрнең авторы** Һади Такташ | **2** | |
| **4.2. Әсәрнең исеме** «Ак чәчәкләр» | **2** | |
| **4.3. Шигырьдә лирик геройның хис-кичерешен табыгыз. Лирик герой** | **6** | |

| | | |
|---|---|---|
| **хисенең сәбәбен аңлатыгыз.** | | |
| Җавап: матурлыкка соклану. Ул тирә-якка хозурланып, аның матурлыгын күрергә тырыша. | | |
| | | |
| | | |
| **4.4. Лирик герой матурлыкны нәрсәләрдә таба?** | **5** | |
| Җавап: Табигатьнең матурлыгында, урамда, кешеләрдә, кешенең күңелендә. | | |
| **4.5. Шигырьдә ямьсезлек нәрсәләрдә чагылыш табуын языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Ямьсезлек җилнең арттан ияреп йөрүендә, кышкы салкында, берәүнең сүгенүендә, туңган тәрәзәдә чагылыш таба. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **5. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтләрен билгеләгез:** | **5** | |
| а) тарихи җыр, дастан, мәкаль, әйтем | | |
| **ә) сатира, юмор, афоризм, сарказм** | | |
| б) хикәя, повесть, роман, новелла | | |
| **в) лирик шигырь, поэма, баллада, нәсер** | | |
| **6. Түбәндә бирелгән әсәрләрнең авторларын тәңгәлләштереп күрсәтегез:** | **4** | |
| 1) Әмирхан Еники а) «Фронтовиклар» | | |
| 2) Мөхәммәт Мәһдиев ә) «Вәхшәт» | | |
| 3) Муса Җәлил б) «Матурлык» | | |
| 4) Һади Такташ в) «Йолдызлы малай» | | |
| 5) Ибраһим Гази г) «Алсу» | | |
| Җавап: 1) б); 2) а); 3) ә); 4) г); 5) в) | | |
| **7. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне кыска инша итеп языгыз.**<br>Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,<br>Танып була аны кылган эшеннән.<br>Дәрдемәнд | **10** | |
| Җавап: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | **Гомум балл**<br><br>**70** | **имза** |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

**Муниципаль этап**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре жаваплары**

**2022-2023 нче уку елы**

**8 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 150 минут**

**Гомуми балл – 70**

| | Максималь балл | Җавап ларга куелган балл |
|---|---|---|
| **1. а) Әлеге билгеләмәгә туры килгән төшенчәне язып куегыз.** | **2** | |
| Нигезендә кайгылы яки көлкеле вакыйга яткан, шигъри формада язылып, телдән әйтелә яки көйләп башкарыла торган лиро-эпик жанрга караган халык авыз иҗаты әсәре ..... дип атала. | | |
| Җавап: Бәет | | |
| **ә) Бу жанрга караган үзегез белгән әсәрләрнең исемнәрен языгыз.** | | |
| Җавап: «Сак-сок бәете», «Сөембикә бәете», «Рус-француз сугышы бәете», «Уңмаган килен бәете» | **5** | |
| **б) Ни өчен бу фольклор әсәрен оригиналь жанр дип атыйлар?** | **4** | |
| Җавап: Бәет татар фольклорына гына хас жанр, оригинальлеге шунда | | |
| **2. а) Кайсы язучы турында сүз баруын билгеләгез.** | **2** | |
| Ул алтын приискалары тоткан. Шулардан алынган табышка татар язучыларының әсәрләрен бастырган, уннарча мәктәпләр тоткан, татар студентларына матди ярдәм күрсәткән, мәчетләр төзегән. Алтын ятмаларын арендага биреп торган башкортларның авылларында да ул үз хисабына мәчетләр төзегән, мәдрәсәләр ачкан. | | |
| Җавап: Дәрдемәнд | | |
| **а) Бу язучының кайсы әсәрләрен беләсез? Шуларны языгыз.** | **5** | |
| Җавап: «Кил, өйрән...», «Видагъ», «Бүзләрем маналмадым» һ.б. | | |
| **3. Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз, сорауларга җаваплар языгыз.** | | |
| Атлар килеп бетте. Садыйк абзый безне тезә башлады. Бусы бик зур бәла икән: инде тигезләп тездем генә дигәндә, я берәүнең аты, кузгалып, алга китеп бара, я баскан урынында тора алмыйча, кире чигенә. Күп азаплардан соң, тезеп җиткерде: – Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар! – дип кычкырып та җибәрде. Ул «һайди»ның «һ»сын әйтеп бетә алмагандыр, атлар әйтерсең канатланып очтылар. Башкалар кая киткәннәрдер, узганнардырмы, артта калганнардырмы, – белә алмадым. Урыныннан кузгалуга, без өч ат – мин, күк бия, тагы бер җирән чабышкы – бер-беребезгә бәреләә язып, янәшә оча идек. | | |
| **3.1. Әсәрнең авторы** Галимҗан Ибраһимов | **2** | |
| **3.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Алмачуар», хикәя | **2** | |
| **3.3. Бу вакыйга ничек тәмамлана? Әсәр герое нинди ялгышлык эшли? Шул турыда языгыз.** | **4** | |
| Җавап: Алмачуарның үлеме белән тәмамлана. Закир беренче тапкыр ярышка чыккан атын артык ерак арага кызу куалап яндыра. | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| **3.4. Әсәр героена  нинди киңәш бирер идегез? Фикерләрегезне языгыз.** | 5 | |
| Җавап: Бар әйбергә чама хисен белергә кирәк. Атыңны яратсаң, үз мәнфәгатьләреңне генә кайгыртмыйча, җиңелү хисабына булса да, бу фаҗиганы булдырмаска тырышырга кирәк. | | |
| **4. Шигъри юлларыннан өзекне укыгыз. Биремнәрне үтәгез.** | | |
| Үзе дәрес тыңлый,<br>Үзе бер дә<br>Тыңламаган кебек итенә,<br>Үзе профессорның дәрсен яза,<br>Үзе аның борнын кәкре итеп<br>Төшереп куя дәфтәр читенә...<br><br>Үзе зачетларын әзерләргә<br>Барыннан да соңрак тотына,<br>Үзе зачетларын башкалардан<br>Алдан бирә, алдан котыла...<br><br>Һәрбер нәрсә аңа, күп көч куймый,<br>Әллә ничек җиңел бирелә,<br>Янар яшьлегенең алсу таңы<br>Үтмәс төсле булып күренә.<br><br>Ул үзенә үзе хуҗа бүген,<br>Үзе акыллы, үзе сөйкемле,<br>Үзе усал,<br>Үзе болай бер дә<br>Усал түгел кебек шикелле... | | |
| **4.1. Әсәрнең авторы** Һади Такташ | 2 | |
| **4.2. Әсәрнең исеме** «Алсу» | 2 | |
| **4.3. Әсәрнең жанры** Поэма | 2 | |
| **4.4. Бу жанрга хас үзенчәлекләрне языгыз.** | 5 | |
| Җавап: Поэмада лирик һәм эпик башлангыч кушылып китә. Поэманың сюжеты була, аңа вакыйгалык хас. Шулай ук поэмада хис-кичереш катламы да көчле. Поэма шигъри (тезмә) формада языла. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **4.5. Әсәр герое «усал» диелә, аның усаллыгы нәрсәдә чагылыш таба? Ул дөрестән дә усалмы?** | 4 | |
| Җавап: Бу усаллык явыз усаллык түгел. Алсу – акыллы усал, кирәк чакта, тиешле урында гына ризасызлыгын белдерергә, усаллыгын күрсәтергә мөмкин. Күп вакытта ул сөйкемле һәм мөлаем. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **4.6. Әсәр герое бәхетлеме? Ни өчен?** | 5 | |
| Җавап: Әйе, ул бәхетле итеп хис итә үзен, чөнки тырыш булганга тормышта аңа бар әйбер дә җиңел бирелә, ул тормышка оптимист буларак карый, тормышны | | |

| | | |
|---|---|---|
| ярата. Иң мөһиме – ул үз-үзенә хуҗа. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **5. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтләрен билгеләгез:** | **5** | |
| а) драма, комедия, трагедия, трагикомедия | | |
| **ә) сатира, юмор, афоризм, сарказм** | | |
| б) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, бәет | | |
| **в) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, новелла** | | |
| **6. Түбәндә бирелгән әсәрләрнең авторларын тәңгәлләштереп күрсәтегез:** | **4** | |
| 1) Габдулла Тукай а) «Тукай» | | |
| 2) Шәриф Камал ә) «Табигать балалары» | | |
| 3) Галимҗан Ибраһимов б) «Милли моңнар» | | |
| 4) Әхмәт Фәйзи в) «Син» | | |
| 5) Сәгыйть Рәмиев г) «Буранда» | | |
| Җавап: 1) б), 2) г), 3) ә), 4) а), 5) в) | | |
| **7. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне кыска инша итеп языгыз.** | **10** | |
| Җиңел түгел, әлбәттә,<br>Яхшы дуслар табуы,<br>Тик үзеңне ярату –<br>Дуслык өчен агу ул.<br>Җәүдәт Дәрзаман | | |
| Җавап: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | **Гомум балл**<br>**70** | **имза** |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

**Муниципаль этап**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре жаваплары**

**2022-2023 нче уку елы**

**9 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**

**Гомуми балл – 70**

| | Максималь балл | Җавап ларга куелган балл |
|---|---|---|
| **1. а) Әлеге билгеләмәгә туры килгән төшенчәне язып куегыз.** | **2** | |
| Танылган шәхесләрнең эш-гамәлләрен, яшәешен мактаган яисә тантаналы, шатлыклы бәйрәмнәр уңаеннан иҗат ителгән әсәр ..... , вафат булган танылган кешеләрне мактау рәвешендә язылган шигъри әсәр ... дип атала. | | |
| Җавап: Мәдхия, мәрсия | | |
| **ә) Әлеге ике жанрның үзенчәлекләрен языгыз.** | **4** | |
| Җавап: Мәдхия исән кешеләргә атап язылган. Мәдхиядә атаклы кешеләргә, остазларга, әти-әниләргә хөрмәт, мәхәббәт, аларны олылау белдерелә. Мәрсиядә якын кешене югалту белән бәйле кайгы, аны юксыну, сагыну хисләре чагылыш таба. Бу әсәрләрдә үлгән кешеләрнең характер сыйфатлары артык күпертеп макталган. | | |
| **б) Ни өчен XVIII гасыр азагы – XX гасыр башы шагыйрьләре бу жанрларда күпләп иҗат иткәннәр?** | **5** | |
| Җавап: XVIII гасыр азагы – XX гасыр башында шагыйрьләр остазына, ата-анасына, иренә, хатынына, авыл мулласына, патшага атап мәдхия, аеруча мәрсия язганнар. Моны бурычлары итеп кабул иткәннәр һәм аны үтәргә тырышканнар. Язучыларның әлеге эш белән артык мавыгып китүен билгеләп, Г. Рәхим, Г. Газиз аларны «мәрсияче шагыйрьләр» дип тә атаганнар. | | |
| **2. а) Кайсы язучы турында сүз баруын билгеләгез.** | **3** | |
| Ул урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, башта – туган төбәгендә, аннары, чирәм җирләргә китеп, Казахстанда эшли. Мәскәүгә барып, М.С. Щепкин исемендәге театр училищесында укый. Училищены тәмамлап кайткач, берникадәр вакыт Минзәлә драма театрында, аннары Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер хезмәтендә була. Алга таба Казан телестудиясендә өлкән мөхәррир һәм «Чаян» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире вазифаларын башкара. Алга таба профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. | | |
| Җавап: Туфан Миңнуллин | | |
| **а) Бу язучының кайсы әсәрләрен беләсез? Шуларны языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Авыл эте Акбай», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Монда тудык, монда үстек», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Гөргери кияүләре» һ.б. | | |
| **3. Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз, сорауларга җаваплар языгыз.** | | |

| | | |
|---|---|---|
| – Нинди әдәп? Исламлык дәгъвасын кылалар да, уртак исламия файдасы өчен монет кадәр акчаларын чыгармакка, алар белән сәгать буе сөйләшергә кирәк. Миңа фән китапларының файдасын инкяр итсеннәр дә, мин мондый кешеләрнең сүзләрен әдәп белән тыңлап торыйм. Исламия файдасы өчен тырышып йөрүне тиле вә буш эштән санасыннар да, мин аларга әдәпле булыйм. Андый гакыллы ишәкләр фән белүне зарарга санасыннар да, мин аларны хурламыйммы? Андый мөселманнарны хурлау гына аздыр. Битләренә төкереп, алардан йөз чөерергә кирәк. | **2** | |
| **3.1. Әсәрнең авторы** Муса Акъегетзадә | | |
| **3.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Хисаметдин менла», повесть | **2** | |
| **3.3. Әсәрдә нинди проблемалар күтәрелә? Шуларны языгыз.** | | |
| Җавап: Әсәрдә түбәндәге проблемалар күтәрелә: шәхес иреге, аның хокукларын яклау, кешедә әдәп-әхлак сыйфатларын булдыру, белем алу һәм һөнәргә өйрәнүне яклау, социаль тигезсезлек, хатын-кыз азатлыгы һ.б. | **6** | |
| **3.4. Әсәрнең идеясен билгеләгез.** | **6** | |
| Җавап: Муса Акъегетзадә әсәрендә татар халкын мәгърифәтле, аң-белемле итеп кенә авыр тормыштан чыгарып, милләтне җәмгыятьнең алгы рәтендә күреп булачак дигән фикер үткәрә. | | |
| | | |
| | | |
| **4. Шигъри юллардан өзекне укыгыз. Биремнәрне үтәгез.** | | |
| Кашлары – ай аның, яңа туган,<br>Йөзе – айның тулган көннәре,<br>Керфекләре – нурлар, кич чәчелгән,<br>Ике күзе – шул кичнең күлләре.<br><br>Үзе ул – диңгез, гыйшык диңгезе,<br>Бар мәхәббәт аңа җыелган,<br>Аңа күк тә, ае, йолдызлары<br>Белән төшеп, сәҗдәгә егылган.<br><br>Бите – кояш, кызарып чыгып килгән,<br>Көлгән чагы – гүя бер сахра,<br>Тавышлары – чын-чын былбыл тавышы...<br>Аһ, үләмен, үләм шул чакта! | | |
| **4.1. Әсәрнең авторы** Сәгыйть Рәмиев | **2** | |
| **4.2. Әсәрнең исеме** «Ул» | **2** | |
| **4.3. Әсәрнең жанры** Шигырь | **2** | |
| **4.4. Лирик геройның хис-кичерешен, аның сәбәбен билгеләп языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Лирик герой гүзәл кызның матурлыгына соклану, аны сөю хисләрен кичерә, сәбәбе – шул кызга гашыйк булуы. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **4.5. Әсәрдә авторның нинди сурәтләү чараларыннан файдалануын языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Чагыштыру: кашлары – ай, йөзе – айның тулган көнәре, керфекләре – нурлар һ.б.<br>Метафора: гыйшык диңгезе.<br>Сынландыру: күк, ае, йолдызлары сәҗдәгә егылган. | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| **5. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтләрен билгеләгез:** | **5** | |
| **а) экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, композиция, чишелеш** | | |
| **ә)** драма, комедия, трагедия, трагикомедия | | |
| б) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, нәсер | | |
| **в) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, газәл** | | |
| **6. Түбәндә бирелгән әсәрләрнең авторларын тәңгәлләштереп күрсәтегез:** | **4** | |
| 1) Шәйхи Маннур а) «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» | | |
| 2) Мирхәйдәр Фәйзи ә) «Кеше китә – җыры кала» | | |
| 3) Фатих Хөсни б) «Муса» | | |
| 4) Мөхәммәт Мәһдиев в) «Сөйләнмәгән хикәя» | | |
| 5) Заһир Бигиев г) «Галиябану» | | |
| Җавап: 1) б), 2) г), 3) в), 4) ә), 5) а) | | |
| **7. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне кыска инша итеп языгыз.** | **10** | |
| Бөркетләр<br>Тауда туа,<br>Батырлар<br>Яуда туа.<br>Роберт Миңнуллин | | |
| Җавап: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | **Гомум балл 70** | **имза** |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

**Муниципаль этап**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре жаваплары**

**2022-2023 нче уку елы**

**10 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**

**Гомуми балл – 70**

| | Максималь балл | Җавап ларга куелган балл |
|---|---|---|
| **1. а) Әлеге билгеләмәгә туры килгән төшенчәне язып куегыз.** | **2** | |
| Персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән һәм гадәттә фаҗига белән тәмамлана торган драматик жанр .... дип атала. | | |
| Җавап: Трагедия | | |
| **ә) Бу жанрга караган үзегез белгән әсәрләрнең исемнәрен языгыз.** | **4** | |
| Җавап: Гаяз Исхакый «Зөләйха», Фәтхи Бурнаш «Таһир-Зөһрә», Нәкый Исәнбәт «Идегәй», Ризван Хәмид «Хан кызы» һ.б. | | |
| **б) Бу жанрның үенчәлекләрен билгеләп языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Трагедия герое гуманистик идеаллар өчен, ирек, азатлык, дөреслек, мәхәббәт өчен көрәшә, ләкин үзеннән олырак көчләрне җиңеп чыга алмый. Трагедиядә тарихка бәйле җитди тема күтәрелә, монологлар күп була. | | |
| 2. а) **Кайсы язучы турында сүз баруын билгеләгез**. | **2** | |
| Ул белемне атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ала. Мәдрәсә белеменә генә риза булмыйча, үзлегеннән, Самарага барып, русча укый. Казанга кайткач, спектакльләр оештырып йөри, шуларда үзе үк баш рольләрне уйный. Мәскәүгә китеп, андагы аристократия белән аралашып зур тормыш мәктәбен үтә. Казанга кайта, әдәби эш белән шөгыльләнә башлый. Ләкин аны кинәт паралич суга, һәм ул гомерлеккә йөри алмас хәлгә килә. Шул вакыттан башлап, ул унтугыз ел буена коляскага беркетелә, киенү, ашау-эчү һәм хәрәкәт итү кебек мәшәкатьләрендә кеше ярдәменә мохтаж булып кала. | | |
| Җавап: Фатих Әмирхан | | |
| **б) Бу язучының кайсы әсәрләрен беләсез? Шуларны языгыз.** | **4** | |
| Җавап: «Нәҗип», «Хәят», «Татар кызы», «Бер хәрабәдә», «Фәтхулла хәзрәт», «Гәрәфә кич төшемдә» һ.б. | | |
| **3. Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз, сорауларга җаваплар языгыз.** | | |
| Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Шулай көйләнде инде карчыкның тормышы: асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм ел буе диярлек тик шуңа әзерләнә. Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, кортын да шулар өчен киптереп куя. Бигрәк тә | | |

| | | |
|---|---|---|
| онықларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын онытa, үзе дә бер бәйрәм итеп кала, бичара. | | |
| **3.1. Әсәрнең авторы** Әмирхан Еники | **2** | |
| **3.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Әйтелмәгән васыять» повесте | **2** | |
| **3.3. Әсәрдә күтәрелгән проблемаларны билгеләгез.** | **5** | |
| Җавап: Ата-ана хакын хаклау, аның алдындагы бурычларны үтәү, түләү, милләтне, телне саклау, туган җир хакын хаклау. | | |
| **3.4. Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Ата-ана-ил бербөтен булып берләштергәндә генә бергә тоташып сакланырга тиеш, шул вакытта милләт тә сакланыр. | | |
| **3.5. Әсәрдәге символик образларны барлап языгыз.** | **4** | |
| Җавап: кылганнар, учак, васыять, камчы. | | |
| **4. Түбәндә бирелгән шигъри юлларны укыгыз. Биремнәрне үтәгез.** | | |
| Дөньялар хафалы, замана буталды,<br>Казанга күрше падишаһ күз салды.<br>Казан эче тынычсыз, дошман бары беленә,<br>Дәүләте бар кешеләр керә кеше теленә.<br><br>Сафагәрәй вакытында бик күп булды сугышлар,<br>Һәркайдан яу килгәчдин авыр булды сулышлар.<br>Гомерем үтте үндүрт ел Сафагәрәй хан белән,<br>Казан шәһәре күңелсез юлда түккән кан белән.<br><br>Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,<br>Шул тынычсыз чакта Сафагәрәем вафат.<br>Ике яшьлек угълым, күзем нуры, колыным,<br>Үтәмешгәрәем калды ятим, былбылым. | | |
| **4.1. Әсәрнең авторы** халык | **2** | |
| **4.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Сөембикә» бәете | **2** | |
| **4.3. Әлеге жанрга хас үзенчәлекләрне языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Нигезендә кайгылы яки көлкеле вакыйга ята, шигъри формада язылып, телдән әйтелә яки көйләп башкарыла, лиро-эпик жанрга караган халык авыз иҗаты әсәре. | | |
| | | |
| | | |
| **4.4. Әсәрдә нинди тарихи вакыйга турында сөйләнелә? Бу вакыйга турында белгәннәрегезне языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Бәеттә Явыз Иванның Казанны алу вакыйгасы сөйләнелә. 1550 елда Мәскәү Казанга һөҗүм итә һәм җиңә, ханлыкның тау ягы дошманга кала. Урыслар Зөя каласын кора башлый. Гаскәр туплау өчен әзерлек эшләрен җәелдерәләр, утрауга кораллар, азык-төлек китерелә. Казанга ультиматум куела. Урыслар, сугыш булмасын өчен, Сөембикәне бирегез, диләр. 1551 елның 11 нче августында Сөембикә мәңгегә Казан белән хушлаша. Аны улы белән башта Зөягә алып китәләр, аннары Мәскәүгә озаталар. | | |
| **4.5. Лирик геройның хис-кичерешен, сәбәбен билгеләп языгыз.** | **4** | |
| Җавап: Лирик герой дошманның дәүләткә һөҗүм итеп аны тар-мар итүе белән бәйле ачыну, чарасызлык белән бәйле борчылу, якыннарының үлүе сәбәпле кайгы-сагыш хисләре кичерә. | | |
| | | |
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| **5. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтләрен билгеләгез:** | **4** | |
| а) драма, комедия, трагедия, трагикомедия | | |
| **ә) лирик шигырь, поэма, баллада, нәсер** | | |
| б) мәрсия, мәдхия, робагый, газәл | | |
| **в) дастан, бәет, мәсәл, мөнәҗәт** | | |
| **6. Түбәндә бирелгән әсәрләрнең авторларын тәңгәлләштереп күрсәтегез:** | **3** | |
| 1) Котб а) «Кыйссаи Йосыф» | | |
| 2) Кол Гали ә) «Сөһәйл вә Гөлдерсен» | | |
| 3) Сәйф Сараи б) «Хөсрәү вә Ширин» | | |
| 4) Мөхәммәдьяр в) «Кыйссас әл-әнбия» | | |
| 5) Рабгузый г) «Нуры содур» | | |
| Җавап: 1) б); 2) а); 3) ә); 4) г); 5) в) | | |
| **7. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне кыска инша итеп языгыз.** | **10** | |
| Батыр булыр өчен, җанда шәфкать кирәк,<br>Батыр була бары мәрхәмәтле йөрәк.<br>Фәнис Яруллин | | |
| Җавап: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | **Гомум балл 70** | **имза** |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

**Муниципаль этап**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре жаваплары**

**2022-2023 нче уку елы**

**11 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**

**Гомуми балл – 70**

| | Максималь балл | Җавап ларга куелган балл |
|---|---|---|
| **1. а) Әлеге билгеләмәгә туры килгән төшенчәне язып куегыз.** | **2** | |
| Әсәрдәге хәрәкәт нигезенә салынган характерлар һәм хәлләр, карашлар һәм тормыш принципларының бәрелешүе ... дип атала. | | |
| Җавап: Конфликт | | |
| **б) Бу төшенчәнең үзенчәлекләрен билгеләп языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Конфликт әсәрдә сюжетның нигезе булып тора. Әсәрдә конфликтлар күп булырга мөмкин, чөнки сюжет тормыш каршылыкларын сөйли. Конфликтлар төрле булырга мөмкин: кешеләр арасында, кеше һәм тирәлек, кеше һәм яшәү рәвеше, кеше һәм җәмгыять, кеше һәм заман, кеше һәм табигать арасында һ.б. | | |
| 2. а) **Кайсы язучы турында сүз баруын билгеләгез.** | **2** | |
| Ул Татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытучы булып эшли. Аннан, Казанга килеп, революцион хәрәкәткә кушылып китә. «Таң йолдызы», «Тавыш» газеталарында эшли. Кулга алынып, Казан, Чистай, Архангел губернасы төрмәләрендә утырып чыга. Революциядән соң Уфада узган Милли мәҗлестә аны Версаль солых конференциясенә делегат итеп сайлыйлар. Әдип шул делегация составында чит илгә китә һәм шуннан Ватанга әйләнеп кайтмый. Ул Харбин, Париж, Берлин, Варшава шәһәрләрендә яши. Икенче Бөтендөнья сугышы башланып, Германия Польшага һөҗүм иткәч, ашыгыч рәвештә Төркиягә чыгып китә. Истанбул, Анкара шәһәрләрендә яши. Истамбулда җирләнә. | | |
| Җавап: Гаяз Исхакый | | |
| **б) Бу язучының кайсы әсәрләрен беләсез? Шуларны языгыз.** | **4** | |
| Җавап: «Кәҗүл читек», «Зөләйха», «Кәләпүшче кыз», «Көз», «Җан Баевич», «Остазбикә», «Ул әле өйләнмәгән иде» һ.б. | | |
| **3. Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз, сорауларга җаваплар языгыз.** | | |
| Кинәт үсеп киттем. Кызны хәзер колак йомшакларына чаклы күрә башладым. Әллә агач ботагында алма белән бергә үстеме икән ул? Битләре нәкъ алма төсле. Чәчен зәңгәр лента белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле. Ә үзе шул кечкенә генә куллары белән үлчәү тәлинкәсе тирәсендә маташкан була. Герләр алып сала, алма тутырыша, мине ичмасам бар дип тә белми. Ачуымны китерсә, чәч үргеченнән тартырмын әле. Уйлавым булды – тартуым булды. Карамас җиреннән карады кызың. Карады, аннары көлеп җибәрде. Тешләре уенчык төсле ап-ак. Алма ашап шулай агарып беткәндер инде ул, дим эчемнән генә. Ә үзем, күземне терәп, карап тик торам. Кыз үлчәү тәлинкәсе тирәсендә бераз маташты да тагын борылды, тагын миңа карады. Бу юлы инде мин аның бит очындагы кечкенә миңенә чаклы күреп калдым. Әйбәт кыз, әйбәт. Безнең авылныкы булса, мин аның хәйләсен табар | | |

| | | |
|---|---|---|
| идем, колак йомшагыннан гына тешләп алыр идем, безнең авылныкы түгел шул. | | |
| **3.1. Әсәрнең авторы** Фатих Хөсни | **2** | |
| **3.2. Әсәрнең исеме, жанры** «Йөзек кашы» повесте | **2** | |
| **3.3. Бу жанрга хас үзенчәлекләрне билгеләгез.** | **6** | |
| Җавап: Повесть хикәядән күләмлерәк жанр. Биредә төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар сурәтләнә. Повестьта берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшә. | | |
| **3.4. Әсәрнең темасын һәм идеясен билгеләп языгыз.** | **6** | |
| Җавап: Әсәрнең темасы – мәхәббәт һәм дуслык. Әсәрдә начар кешеләр, гаделсезлек саф күңелле кешеләрнең дә күңелен тупасландыра, кызу баштан уйламый эшләнгән эшнең нәтиҗәсе начар була, әшәкелеккә әшәкелек белән җавап бирү начарлыкны арттыра гына бара дигән фикер үткәрелә. Бу әсәрнең идеясе була. | | |
| **3.5. Әсәрдә тасвирланган бәхетсез мәхәббәтнең сәбәбе нәрсәдә? Фикерләрегезне языгыз.** | **4** | |
| Җавап: Госманның дусты Айдарга хыянәте Айдар белән Вәсиләне бәхетсез итә | | |
| **4. Түбәндә бирелгән шигъри юлларны укыгыз. Биремнәрне үтәгез.** | | |
| Хуш, акыллым, соңгы сәламемне<br>Юллыйм сиңа җилләр аркылы.<br>Барсын сиңа кайнар сәлам булып<br>Йөрәгемнең сүнмәс ялкыны.<br><br>Киткән чакта Казан Кремле<br>Магнит төсле тартты уемны.<br>Син балконнан мине яулык болгап<br>Озатасың төсле тоелды.<br><br>Син торасың төсле миңа карап,<br>Аерылганга бераз көенеп;<br>Хыялымда сине соңгы кабат<br>Суырып үптем, яшькә төелеп.<br><br>Киттем, дускай, кайнар өмит белән,<br>Дошман явын җиңеп кайтырга.<br>Батырларча каты сугышырга,<br>Тап төшерми изге антыма. | | |
| **4.1. Әсәрнең авторы** Муса Җәлил | **2** | |
| **4.2. әсәрнең исеме, жанры** «Хуш, акыллым» шигыре | **2** | |
| **4.3. Лирик герой кем белән хушлаша? Әсәр кемгә багышлап язылган?** | **5** | |
| Җавап: Лирик герой сөйгәне (хатыны) белән хушлаша. Муса Җәлил шигырьне хатыны Әминәгә багышлап язган. | | |
| | | |
| | | |
| **4.4. Лирик геройның хис-кичерешен, сәбәбен билгеләп языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Лирик герой дошман явын җиңеп кайтуга өмет хисе белән яши, чөнки ул ил хакына батырларча сугышырга әзер. Шул ук вакытта ул туган ягыннан, сөйгәненнән аерылу белән бәйле сагышлана, кабат аларны күрергә өметләнеп юану хисен кичерә. | | |
| **4.5. Әсәрнең төп идеясен языгыз.** | **5** | |
| Җавап: Әсәрдә сөйгәненә булган мәхәббәте, туган илен ярату хисе кешене өметләндерә, аңа дошманны җиңеп кайтырга, батырларча сугышырга көч-дәрт | | |

| | | |
|---|---|---|
| бирә дигән фикер үткәрелә. | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| **5. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтләрен билгеләгез:** | **5** | |
| а) мәрсия, мәсәл, робагый, газәл | | |
| **ә) дастан, бәет, мәдхия, мөнәҗәт** | | |
| б) хикәя, повесть, роман, новелла | | |
| **в) лирик шигырь, поэма, баллада, нәсер** | | |
| **6. Түбәндә бирелгән әсәрләрнең авторларын тәңгәлләштереп күрсәтегез:** | **3** | |
| 1) Муса Җәлил а) «Ак чәчәкләр» | | |
| 2) Һади Такташ ә) «Өф-өф итеп» | | |
| 3) Хәсән Туфан б) «Кошчык» | | |
| 4) Гамил Афзал в) «Сабантуй» | | |
| 5) Ренат Харис г) «Кайсыгызның кулы җылы?» | | |
| Җавап: 1) б); 2) а); 3) г); 4) ә); 5) в) | | |
| **7. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне кыска инша итеп языгыз.** | **10** | |
| Бәхеттән һәм мәхәббәттән арган мәлдә,<br>Тапмый бәндә, күрми башлый җирдә мәгънә.<br>Әхсән Баян | | |
| Җавап: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | **Гомум балл**<br>**70** | **имза** |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |